ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21 февраль, 2018 ел № 23/9

Шәһәр Советының 2016 елның
09 ноябрендәге «Җир салымы турында»
11/6 санлы Карарына үзгәрешләр кертү
хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсенә нигезләнеп, Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2016 елның 09 ноябрендәге «Җир салымы турында»11/6 санлы Карарын (Шәһәр Советының 2016 елның 15 декабрендәге 13/7, 2017 елның 15 декабрендәге 21/7 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге эчтәлектәге 3.1. пункты белән тулыландырырга:

«3.1. «Автомобиль төзелеше сәнәгате» төрендәге куллануга рөхсәт ителгән һәм авыр йөк автомобильләре җитештерүче оешмалар милкендә булган җир кишәрлекләренә, 2014 елның 31 декабрендәге «Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» 488-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә төзелгән махсус инвестиция контракты кысаларында җир кишәрлекләре сәнәгый җитештерү өчен кулланылган очракта, җир салымының киметелгән ставкасын 0,1 процент күләмендә итеп билгеләргә.

Киметелгән ставка махсус инвестиция контракты төзелгән айның беренче көненнән башлап, махсус инвестиция контрактының гамәлдәге вакытында, әмма 10 елдан да озаграк булмаган чорда кулланылыа.».

2. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев